Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 6**

Шумково авылы 15.04.2026 ел.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 07.05.2018 елның № 05 Масловка «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» Шумково номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә күпьеллык хезмәт өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган кызыксындыруны түләү тәртибе турында” Нигезләмәне раслау хакында 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгу сәбәпле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең,

рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2018 елның Шумково «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 05 номерлы карарына (29.09.2020 ел, № 13; 14.10.2024 ел № 16; 04.02.2025 ел №1 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме һәм шартлары» 1 нче кушымтада авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 23 201 сум билгеләргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме» 2 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389,0» санын «16 928,0» санына алмаштырырга;

2. Карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнвардән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карар түбәндәге адрес буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең махсус мәгълүмат такталарында урнаштырылырга тиеш: Шумково авылы, Узэк урамы, 22, Олы Укмас авылы, Узэк урамы, 42, Хутор авылы, Яшләр урамы, 10, Ошняк-Качкалак авылы, Оске урамы, 6, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы Хокукый Мәгълүматының Рәсми Порталы"нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыйлаҗиева

СОВЕТ ШУМКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000845 ШУМКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ